Май • 2021 ел • № 5 (41)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы

# Бөек Җиңүгә – 76 ел!

Иксез-чиксез илебезнең бер генә гаиләсенә дә Бөек Ватан сугышы җиле кагылмый үтмәде. Һәр йортның да үз тарихы, анда туганнарының һәм якыннарының фотосурәтләре, башка ядкарьләре кадерләп саклана. Совет солдатының планетага тынычлык һәм ирек алып килүенә 76 ел узды. Шул вакыттан күпме генә еллар узса да, халкыбызның бөек батырлыгын, тынычлыкның нәрсә бәрабәренә яулап алынуын без һәрвакыт истә тотачакбыз.

Бөек Җиңү көнендә безнең гимназия укучылары да туган илебезне яклап безгә матур, тыныч тормыш бүләк иткән сугыш һәм тыл ветераннарыбыз каршында баш иеп, аларга чиксез рәхмәтләрен белдерделәр.

Бөек Җиңү котлы булсын!






Мансур ШИҺАПОВ

## *Җиңү көне җиңел бирелмәде...*

Яшь каеннар яфрак ярган чакта,
Яшь каендай зифа егетләр,
Ил бурычын иңнәренә салып,
Утка төренеп, яуга керделәр.
Җиңү көне җиңел бирелмәде,
Җыр җырланмый шөһрәт-дан өчен.
Йөрәк елый Муса, Алиш өчен,
Егермеләп миллион җан өчен!
Тарих шаһит: үлмәс Карбышевлар
Әверелә бозга – ил сатмый.
Татар улы – батыр Газинурлар –
Күкрәкләре белән ут каплый.
Яңгыра, җыр, газиз илем өчен,
Рәхмәт, Ватан, җиңдең, талпындың.
Яңгыра, җыр, горурлыгы булып,
Батырлыгы булып халкымның!

# Гимназиядә – семинар!

Дөнья турында белемнең берничә фәнгә бүленеп тармаклануына карамастан, аларның мөһим уртак ягы бар – дөнья кеше тарафыннан танып беленә. Кеше өчен дөньяда булган нәрсә телдә чагыла. Менә шушы күзлектән чыгып, «Туган (татар) тел һәм әдәбият» фәннәренең «Әйләнә-тирә дөнья» фәне белән бәйләнеше зур. Без М.Вахитов исемендәге №2 гимназия базасында «Билингваль белем бирү шартларында уку әсбапларының тоткан урыны һәм әһәмияте» исеме астында татар мәктәпләрендә эшләүче башлангыч сыйныфлар һәм туган (татар) тел һәм әдәбият укытучылары өчен Беренче республикакүләм семинар оештырдык. Әлеге семинарда профессор, педагогика фәннәре докторы, А.А.Плешаков, М.Ю.Новицкая авторлыгындагы 1–4 сыйныфлар өчен «Әйләнә-тирә дөнья» әсбапларын татар мәктәпләрендә укучы балаларга файдалы итеп яраклаштырып төзегән дәреслекләр авторы Җәүдәт Абдулла улы Хөсәенов катнашты. Семинар материаллары, җыентык итеп итеп бастырылып, укытучыларга таратылды. Әлеге җыентыкта Актаныш, Әгерҗе, Тукай, Мөслим, Сарман, Кукмара, Балтач, Балык Бистәсе районнары, Казан, Алабуга, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләре укытучыларының фәнни хезмәтләре: дәрес эшкәртмәләре, мәкаләләре, дәрестән тыш чаралары дөнья күрде.

Семинарда «Тылсым» театр түгәрәге (җитәкчеләре А.Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы татар дәүләт драма театрының һәм Татарстанның атказанган артистлары Э.Ф.Шиһапова, Ч.Р.Садыкова) Т.Миңнуллинның җыелма әсәрләреннән «Булмас димә!» тамашасын күрсәттеләр. Укучыларның уйнавы искиткеч оста, әсәр күтәргән проблемалар актуаль, теманың семинар эчтәлегенә аваздаш булуы бик отышлы булды.

Башлангыч сыйныфның 1–2 сыйныфлары өчен А.Х.Кадирова һәм Я.Г.Газизова күрсәткән ачык дәресләрнең тәрбияви яктан файдалы, методик яктан грамоталы төзелгән булуын ассызыкларга кирәк.

Ә.Ә.Сәгыйтова, Ф.Г.Фәйзуллина, Р.Ф.Солтанова әзерләгән ачык чараларда укучылар эшчәнлекләре мавыктыргыч, кызыклы, файдалы итеп оештырылуы, укучыларның матур итеп туган телдә аралашулары игътибарга алынды.

«Әйләнә-тирә дөнья» фәнен өйрәнүнең төрле кызык юлларын табарга мөмкин. Нафикова Ландыш Хопбулловна, Хаматова Ләйсәния Бариевна әзерләгән «Тамчы-шоу» интеллектуаль уены моның ачык дәлиле булды.

Алга таба семинар түгәрәк өстәл артында әңгәмә белән дәвам итте. Җ.А. Хөсәенов 1–4 сыйныфлар өчен үзгәртеп бастырылган «Әйләнә-тирә дөнья» уку әсбапларының үзенчәлекле якларына тукталды. Дәреслек авторы керткән мәгълүматлар татар мәктәпләрендә укучы балаларга халыкның мәдәниятен һәм рухи кыйммәтләрен үзләштерүгә мөмкинлек тудыру өстенә, туган телнең байлыгыннан оста файдаланырга өйрәтүе һәм тарихи җирлеккә нигезләнүе белән күпкә файдалы. Татар халкының яшәү рәвеше, онытыла төшкән йолалары, гаилә кыйммәтләре, туган ил төшенчәсе татар балаларна үз телендә аңлатылырга тиеш. Төпле белем белән тәрбия янәшә алып барылган очракта гына әхлаклы кеше тәрбияләнә.

Җ.А.Хөсәеновның Татарстан китап нәшрияте тарафыннан 2017 нче елда нәшер ителгән «Русча-татарча география сүзлеге» Э.Ә.Нурисламова чыгышында игътибарга алынды.

Семинар бик файдалы булды. Килгән укытучылар: «Гимназиянең төзеклегенә, матурлыгына; акыллы, сәләтле, бик матур татарча сөйләшә торган укучыларга, энергияле укытучыларына сокландык. Фәнни-методик яктан үзебез өчен күп мәгълүмат алдык», – диделәр. Бу безнең хезмәтебезгә кадерле бәя булды .

**Энҗе Әзһәм кызы НУРИСЛАМОВА**





# Яшьләр кемне үз итә?

Һәр чорның яшьләр генә яратып тыңлый торган җырлары, кумирлары була. Кайвакыт өлкән буын кешеләре яшьләрне аңламый, аларны зәвыксыз, дип тәнкыйтьләргә ярата. Бүгенге яшьләрне зәвыксыз дип уйларга ашыйкмыйк, чөнки заманасы нинди, җыры шундый инде аның. Әйе, хәзер колагына наушниклар тыккан егетләр-кызлар ниндидер субкультура вәкилләренә охшыйлар, аларның кайберләре корея җырчыларын тыңлыйлар. Минем танышларым арасында мәктәпне тәмамлагач, Кореягә барырга теләүчеләр дә бар.

Ә шулай да яшьләр нинди җырлар ярата соң? Монда уртаклык юк, чөнки интернет челтәрендә җыр яңгырау белән, һәркем үз фикерен җиткерергә ашыга: кемгәдер җырчының киенү стиле, кемгәдер музыкасы, кемгәдер видеороликлары ошарга, я ошамаска мөмкин. Бүген популяр буласы килгән җырчы «кешечә» киенмәскә, үзенә генә хас фишка белән тамашачаны җәлеп итәргә ярата: берәүләр ак линза кия, кайберләре тау башына пианино менгереп куеп, шунда уйный, кыскасы фантазияң нәрсәгә җитә инде. Шул ук вакытта танылган җырчылар да яшьләрдән калышмаска тырыша. Николай Басков Дана Милохин (Даниил Милохин) белән яздырган клибы белән берара кызыксыну уятты. Дана Милохинга килгәндә, ни өчен ул тамашачыга ошый? Чөнки ул үзенең берникадәр наданлыгыннан оялмый, башкаларга кушылып көлә белә. Ябык кына артистның бөкләнеп урындыкта утыруы да – гадәти күренеш, шуңа күрә ул гадәти яшьтәш ролендә тамашачыга ошый. Анын аккаунтына унике миллионнан артык кеше язылган. Ул рәхәтләнеп акча эшли, шуңа күрә аңа артык акыллы булып күренү кирәкми.

«Голос-дети» тапшыруында жюри булып утыручы Егор Кридның, Бастаның да популярлыгы киң. Егор Крид үзе төшкән фильмнарындагы геройлары кебек ниндидер романтик җырчы булып кала, шуңа күрә яшьләр аннан ниндидер космик герой ясарга яраталар.

Җырларның эчтәлегенә килгәндә, никтер сүгенү сүзләре кергән җырлар популяр. Россиянең танылган рэп-башкаручысы Моргштернның җырлары бик популяр. Моргенштерн – үз вакытының продукты. Моргенштерн – ул заманча уңыш. Ул – яшьләрне котырта, шуңа аның белән кызыксыналар, ләкин аның турында зурлар яшьләрдә зәвыксызлык тәрбияли, диләр.

Дораны (Дарья Сергеевна Шиханова) да яшүсмерләр яратып тыңлый. «Дораның тавышы йомшак, назлы. Аның матур җырлары, шулай ук киенүе күбесенә ошый, актив кыз, аның артыннан күзәтергә кызык», – диләр.

Хәзер яшьләр инглиз телендә иркен сөйләшәләр , шуңа күрә чит телдәге җырлар популяр. Америка җырчысы Билли Айлишның Трамп белән булган низагыннан соң бик күп яшьләр аның тормышын күзәтә, җырларын тыңлый башладылар.

Димәк, яшьләр яратып тыңлый торган җырларның үз тарихлары бар. Яңа җырлар туа тора, тормыш алга бара. «Җырның ертыгы юк», аның бик сирәге вакытлар узу белән сакланып кала, ә болай ул җырлар яшьләрнең тормыш бизәге, уртак мавыгуы гына, шуңа күрә, өлкәннәр борчылмасын иде, дип уйлый идем. Фикерем үзгәрде: Казан гимназиясендәге фаҗигадан соң мин музыканың җимергеч көч икәнен аңладым. Теләсә нәрсә тыңлап, үзеңне җәфаламаска кирәк. Синең нинди эчтәлектәге җырны тыңлавыңнан яныңдагы кешеләрнең сиңа мөнәсәбәте формалаша, синең үзбәяң үзгәрә. Сәламәт яшәү рәвешен эзләгән кебек, кеше дәрәҗәсен төшермәслек җыр тыңларга кирәктер, мөгаен.

**Алия НУРИСЛАМОВА**

Гимназия күрке

# Безнең Диана булдырды!



Татар теленнән VIII Халыкара олимпиада призеры исеменә лаек булган 9нчы сыйныф укучысы Демашина Диана шәһәребез, гимназиябез данын яклады. Бу уңышка ул әдәбият фәненнннән системалы рәвештә шәһәр олимпиадаларында катнашып килү нәтиҗәсендә иреште. Ул үзенең укытучылары Валеева Суфия Василовнага һәм Нурисламова Энҗе Әзһәмовнага чиксез рәхмәт хисләрен белдереде.

Предмет буенча белемнәрдән кала, Суфия Василовна белән берлектә эшләгән проект эше актуальлеге, гимназиянең тарихы белән бәйле булуы белән Дианага зур өстенлек биргән. Ә инде чыгышының ахырында «Икенче гимназиям» җырын акапеллага башкаруы Диананың көндәшләренә шанс калдырмаган.

Гимназия директоры Гарифуллин А.Х., Диананы котлап, истәлекле бүләкләр тапшырды .

Афәрин, Диана! Сиңа яңаданяңа үрләр яуларга уңышлар юлдаш булсын!

**Азалия ӘМИНОВА**



# Татар малае

Татар малае нинди булырга тиешлеге хакында сорасалар, һич иренмичә, гимназиянең 2 нче сыйныфына юл тотыгыз. А.Х.Кадирова сыйныфында укучы Вәлиуллин Кәрим «Татар малае – 2021» шәһәркүләм бәйгесендә өченче урын алган!

Кәрим тырышып укый, саф татарча сөйләшә, җырлый, спорт белән шөгыльләнә, зурларга карата ихтирамлы. Менә шундый ул безнең татар малае!

**Адилә ХАНОВА**

## Рәхмәт хаты

Сугыш... Нинди дәһшәтле, куркыныч сүз, авыр сүз! 27 миллион кешенең гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән... Миллионлаганнарның яшьлек елларын, балалык чорын, тигез гаиләдә яшәүне урлаган еллар...

Бөек Ватан сугышы чоры халык өчен зур сынау еллары булды. Бөек Ватан сугышын, фашист илбасарларына каршы халкыбызның героик көрәшен бөтен Җир шары хәтердән мәңге җуймас. Ил өчен авыр сынау көннәрендә халкыбыз бергә тупланды. Сугышның беренче көннәреннән үк русы, татары, чувашы, удмурты, башка милләт кешеләре туган илен – Ватанын сакларга күтәрелде. Бөек Ватан сугышында халыкның батырлыгы, Туган илгә бирелгәнлеге, чиксез мәхәббәте, төрле милләт халыкларының бердәмлеге күренде.

Безгә тыныч тормыш, аяз көннәр бүләк иткән өчен, үзегезне кызганмавыгыз, тормышыгызны куркыныч астына куйганыгыз, батырлык күрсәткәнегез өчен, антыгызны, сүзегезне тотканыгыз өчен сезгә мең рәхмәтемне белдерәм, сезгә баш иям! Ватан өчен, безнең Җиңү өчен көрәшкән һәркемгә мәңгелек дан!

**Камилә ЕВГРАФОВА,**
*9а сыйныфы*

## Билгесез солдатка хат

Исәнме, кадерле Татар солдаты!

Технологияләр кискен үскән заманда, мин сиңа хат язам. Безнең вакытта хат язучылар бик аз калды инде, бөтенесе гаджетларда яки компьютерларда утыра, әмма миңа бу берничек тә комачауламый. Кайчандыр, син фронтта булганда, сез хатларны көтеп кенә торгансыздыр, әниләрегездән, яраткан кешеләрегездән хәбәр көтү бик авыр бит ул. Мин сез кичергән авырлыкларны күз алдыма да китерә алмый. Ничек шулай яшәдегез сез, ничек кеше булып калдыгыз? Моңа карамастан, сезнең батырлыгыгыз һәрвакыт безнең йөрәгебездә булачак, ул безне авыр чакларда коткарып торыр дип уйлыйм .

Хәзерге вакытта син – Ветеран. Әйе, Ветеран сүзен мин баш хәрефтән язам, чөнки сез, солдатлар, үзегезнең гомерегезне куркыныч астына куеп, киләчәк турында уйладыгыз, сез киләчәк буыныгызның тынычлыкта яшәүләрен теләдегез. Хәзер инде син бик яшь тә түгел, әмма безнең XXI гасырда син - чын Батыр, синнән көчлерәк кеше дә юк, хәтта синнән башка булмаслар иде алар.

Җиңүчеләр, Сезнең батырлык үлемсез! Сездән башка без тормышыбызны берничек тә күз алдыбызга китерә алмыйбыз. Солдатлар безгә тормыш бирделәр дип әйтеп тә була, һәм бу бер дә ялган түгел. Сезне Туган ил бердәм итте. Бердәмлегегез безне җиңүчеләргә әйләндерде.

Рәхмәт сиңа, кадерле солдат! Курыкмаганыңа, бөтен нәрсәне ташлап, Илебезне яклаганга зур рәхмәт!

**Аделина КӘБИРОВА,**
*9а сыйныфы*

## Минем бабам!

Бөек Ватан сугышы... Мөгаен бу сугыш беркемне дә битараф калдырмыйдыр, чөнки ул һәр гаилә ишеген шакый, борчу-хәсрәткә күмә, күпме балаларны ятим, аналарны тол калдыра.

Минем бабам – Нәбиев Әүхәт Хәйретдин улы сугышта катнашкан. Тумышы белән Адай авылыннан. 1925 елнын 15нче июнендә туган .

18 яше тулган егетне 1943 елда Бөек Ватан сугышының кайнар урынына җибәрәләр. Украина фронтында сугыша ул. Смоленск шәһәрен азат итүдә катнаша. Каты бәрелешләр вакытында яралана. Туган авылына демобилизацияләнә. Фрунзе исемендәге колхозда төрле эшләрдә эшли.

Ләкин сугыш яралары үзен нык сиздерә, шуңа да лаеклы ялга инвалидлык буенча иртәрәк чыга. Тормыш иптәше белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр.

Мин үземнең бабам белән горурланам, чөнки ул үз ватанын саклауда катнашкан чын кеше!

**Идалия ЮНЫСОВА,**
*9а сыйныфы.*

## Исәнмесез, билгесез Солдат!

Бөек Җиңүнең 76 еллыгын бәйрәм итәбез.

Һәр буынның үз язмышы, үз санаулары. Сезгә бик күп сынаулар аша үтәргә туры килде. Сез Бөек Ватан сугышында дөньяны зур афәттән коткарып калдыгыз, туган илебезнең бәхетле тормышы хакына фидакарьләрчә хезмәт иттегез. Без сезнең белән горурланабыз һәм сезнең кыюлык, чыдамлык һәм Ватанга мәхәббәт көченнән үрнәк алабыз.

Безнең бүгенге тыныч тормышыбыз рухи казанышларыбыз нәкъ менә шуның нәтиҗәсе.

Батырлыгыгыз, түземлелек һәм сабырлыгыгыз, дуслык һәм кардәшлегегез өчен зур рәхмәт. Сезнең алда баш иябез!

**Динар Фазлыев,**
*9а сыйныфы*

## Исәнмесез, ветераннар!

Сез һәрвакыт безнең өчен батырлык, тугрылык, Ватанга мәхәббәт үрнәге булдыгыз.

Сезнең тарафтан күпме авыр юллар үтелгән. Сезнен юлларыгыз бик авыр булган. Әмма сез бернигә дә карамый алга бардыгыз, чөнки сезнең бер максатыгыз бар иде - илебезне дошманнардан азат итү.

Сез кышларын туңдыгыз, сезне җәйге кояш яндырды, күз алдыгызда йортлар һәм агачлар янды, шәһәрләр җимерелде, әмма сез алга таба бардыгыз. Фашистларны Берлинга кадәр куып житкереп, Рейхстаг өстенә кызыл флаг кутәрдегез.

Рәхмәт сезгә, ветераннар, сезнең батырлык өчен, мин һәм минем дусларым тыныч күк астында яшәгән өчен. Сезнең тормышыгыз имин булсын, сәламәт булыгыз.

**Айнур ШАЕХОВ,**
*9а сыйныфы*

Минем гимназиям
**Баш мөхәррир** Алия НУРИСЛАМОВА • **Редакция әгъзалары:** Азалия ӘМИНОВА • Адилә ХАНОВА • Мәрьям РИЗАТДИНОВА • Әминә ШАКИРОВА • Данис ДАМИНОВ • Ләйсән КӘРИМОВА • Камилла ЮСУПОВА • Зәринә СӘХӘБЕТДИНОВА • **Редактор-координатор:** Э. А. НУРИСЛАМОВА